Совет Старочукалинского сельского поселения Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы

422480 Республика Татарстан с.Старые Чукалы ул.Коминтерна д.21 тел/факс 34-1-12
ОГРН 1021606556850 ИНН 1617000612
=====================================================

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

Иске Чокалы

19 май 2020 ел № 56/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының «Физик затлар милкенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Татарстан Республикасы территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Уставы буенча Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чокалы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 15.11.2019 ел, №52/1 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2 пунктта:**

**1 пунктчага** түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

составына бер генә торак йорт керә торган Бердәм күчемсез комплекслар исемлеге;

мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, яшелчәчелек, бакчачылык яки шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яки корылмалары.»;

**3 пунктның дүртенче абзацын төшереп калдырырга.**

2. Әлеге карарны Иске Чокалы авыл җирлеге территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм түбәндәге адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга: http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин ул басылып чыккан көннән бер айдан да иртәрәк түгел.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чокалы авыл җирлеге башлыгы: Р.Р.Низамутдинов